**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2016 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Исмәгыйлев Нәҗип Фәйзрахман улына (Нәҗип Нәккашка) – шәмаилләр, шагыйрь Г.Тукайның шигъри юллары язылган ләүхәләр (гарәп шрифты белән текстлар язылган картиналар) циклы һәм Казан шәһәренең «Ярдәм», Татарстан Республикасы Түбән Кама районының Шәңгәлче авылы мәчетләрен бизәгән (гарәп каллиграфиясе) өчен;

2) Моратов Газинур Васикъ улына (Газинур Моратка) – «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2014 ел;

3) түбәндәге авторлар: Артамонов Илья Николаевич (рәссам-проектлаучы), Леухин Александр Петрович (рәссам-проектлаучы), Вәлиуллин Фәрит Рәшит улы (рәссам-монументчы), Шиһабетдинов Рашид Садрый улы (рәссам-монументчы), Щетинин Игорь Васильевич (рәссам-монументчы), Ситдыйков Айрат Габит улы (Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры), Хәйретдинов Рамил Равил улы (Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты директоры), Бугров Дмитрий Геннадьевич (археолог) кергән коллективка – «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» («Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкларга сузылган юл») сәнгать-пространство экспозиция инсталляциясен иҗат иткән өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 22 апрель
№ ПУ-375

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ